# *Татар телен мультфильмнар аша саклау һәм үстерү*

Адиева Мөслимә Азат кызы
«Адымнар - Казан» мәктәбе
11 сыйныф
Фәнни җитәкче:
Ханнанов Рамил Гомәр улы

# *Максат һәм бурычлар*


**Без проект эшебезнең *максаты* итеп туган телебезгә мультфильмнар тәрҗемә итүне, татар телендә видео- һәм аудиохикәяләр туплаган сайт булдыруны билгеләдек.**

**Максатка бәйле рәвештә, түбәндәге *бурычларны* чиштек:**
**– мультипликация жанры ничек килеп чыкканын белү;**
**– татар, рус, инглиз телләрендәге мультфильмнарны чагыштыру;**
**– татар телендәге мультфильмнарны классификацияләү;**
**– мультфильмнарнын файда һәм зыянлылык дәрәҗәсен билгеләү.**

# Мультипликация жанрының тарихы


Мультипликациянең төрле техникалары бар: *курчак* һәм *компьютер* анимациясе. Анимацион студияне беренчеләрдән булып 1915 елда Барр һәм Брей дигән кешеләр ачып җибәрә. Беренче тавышлы мультфильмны, «Вилли пароходын», 1928 елда Уолт Дисней төшерә.

Рус анимациясенең туган елы – 1911 ел. Беренче рус мультфильмын Владислав Старевич төшерә.



**Мультфильмнар балаларның үсешенә һәм аңына каты *тәэсир* ясый. Матур, образлы, мавыктыргыч, гади мультфильмнар безнең аңда яхшылык һәм явызлык, тәрбиялелек һәм тәртипсезлек турында күзаллау тудыра. Бу мультфильмнардагы вакыйгалар тәрбия бирә, фикерләү дәрәҗәсен, фантазияне үстерә, дөньяны танып белергә өйрәтә.**











**Татар телендәге мультфильмнар сөйләмне баета, милләтебезгә карата горурлык һәм мәхәббәт хисе, хезмәткә һәм белемгә омтылыш уята.**
**Шулай ук алар безне эти-әниләребезнең сүзен тыңларга, сер сакларга һәм тугры булырга өйрәтә; татар телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен, балалар һәм өлкәннәрнең үзара мөнәсәбәтләрен сакларга, үстерергә ярдәм итә.**




Татарча мультфильмнар
Мультфильмнар
Аудиомультфильмнар
Проект турында
Мультфильмнар
Татар телен, татар халкының мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен, балалар һәм өлкәннәрнең үзара мөнәсәбәтләрен саклау, үстерү максатына юнәлдерелгән мультфильмнар бүген шактый киң таралыш алды. Аларның күбесе тыңлап аңлау технологиясе аша татар теле күнекмәләрен үстерүне, сөйләшү нигезләрен формалаштыруны күздә тота.
Безнең проект – туган телебезне саклау һәм үстерү өчен күңелле һәм уңайлы бер юл. Сайтыбызда җыелган татар телендәге видео- һәм аудиохикәяләр ярдәмендә яңа буын телебезне табигый итеп үзләштерергә, аңларга һәм сөйләшергә өйрәнә ала.
әкият
Фыйфый турында әкият
11 мин
2026
әкият
Аю баласы Зирәккәй турында әкият
17 мин
2026
мультфильм
Тиз вакыт
2 мин
2026


Татарча мультфильмнар
Мультфильмнар
Аудиомультфильмнар
Проект турында
Аудиомультфильмнар
Тыңлап аңларга һәм күзаллау сәләтен үстерергә булышучы әкиятләр
Чикләнчек
20 мин

Татарча мультфильмнар

Мультфильмнар Аудиомультфильмнар Проект турында

# Проект турында

Татар телен өйрәнү, үстерү һәм популярлаштыру

## Безнең максат

Бу проект татар телен өйрәнү, үстерү һәм популярлаштыру максатыннан чыгып эшләнә. Без балаларның һәм өлкәннәрнең татар телендә мультфильмнар карап, аудиохикәяләр тыңлап, телне үстерергә ярдәм итәбез.

Безнең сайтта сез борынгы татар халык әкиятләрен, заманча хикәяләрне һәм балалар өчен махсус ясалган контентны табарсыз.

# *Игътибарыгыз өчен рәхмәт!*